ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 545 от «15» 05 2017 г.

2017 елда Мамадыш муниципаль районы
территориясендә бердәм дәүләт имтиханын
һәм бердәм республика имтиханын
үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.02.2017 елның 18 февралендәге №264-р күрсәтмәсе нигезендә, урта гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт йомгак аттестациясен уздыру максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 13 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Муниципаль район башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ (Габдрахманов И. Н.):

- 2017 елда бердәм дәүләт имтиханын үткәрүне тәэмин итәргә;
- 2017 елда «Татар теле» һәм «татар әдәбияты» урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар өчен « татар теле» һәм «татар әдәбияты» фәннәре буенча бердәм республика имтиханын үткәрергә;
- үз компетенциясе чикләрендә бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын үткәрүне мәгълүмати һәм норматив - хокукый тәэмин итүне гамәлгә ашырырга;
- бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын инструктив-методик, оештыру-технологик һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

2. Дәүләт йомгаклау аттестациясе чорында муниципаль районда имтихан үткәрү пункты итеп Мамадыш шәһәренең 3 нче урта мәктәбен билгеләргә.

3. Финанс-бюджет палатасы (А.М. Сергеев) «Мәгариф бүлеге»МКУ чыгымнар сметасы нигезендә бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын оештыруга һәм үткәрүне финанслауны күздә тотарга.

4. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлегенә бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын уздыру пунктлары янындагы территорияләрдә җәмәгать тәртибен саклауда һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. « Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССОсын (Д. ф. Хаҗиев) Бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын уздыру пунктларында медицина персоналының кизү торуын оештыруда ярдәм итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Э.Фәттахов